СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**Решение**
**28.10.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 140**

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яисә) озак вакытка файдалану (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе турында, шулай ук күрсәтелгән исемлеккә кертелгән мөлкәтне арендага бирү тәртибе һәм шартлары турында

2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында», 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнары, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы милкендә булган мөлкәт, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга милек тапшыру механизмын тәртипкә салу максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. 1 нче кушымта нигезендә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына биләүгә һәм (яисә) озак вакытка файдалану (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру, алып бару, мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен расларга.

2. 2 нче кушымта нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка

китерүче оешмаларга, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытка (шул исәптән аренда түләвенең ташламалы ставкалары буенча) файдалану өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган, муниципаль мөлкәт исемлегенә кертелгән, муниципаль мөлкәтне арендага бирү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасына бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск Башлыгы**
**муниципаль районы**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**